В. МАЯКОВСКИЙ



НӘРСӘ УЛ ЯХШЫ, НӘРСӘ УЛ НАЧАР

ТАТКНИГОИЗДАТ · 1954

В. МАЯКОВСКИЙ

НӘРСӘ УЛ ЯХШЫ, НӘРСӘ УЛ НАЧАР



ХУДОЖНИГЫ
А. ПАХОМОВ

ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
КАЗАН 1954

* * *

Редакторы *Мәхмүт Хөсәен*

Тышлык художнигы *Э. Е. Дьячкова*

* * *

В. МАЯКОВСКИЙ

ЧТО ТАКОЕ ХОРОШО
И ЧТО ТАКОЕ ПЛОХО

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе *Ә. Фәйзи*

Художество редакторы *Б. М. Альменов*

Техн. редакторы *Ф. Г. Нурутдинов*

Корректоры *Р. Г. Гимадетдинова*

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН


Наборга бирелде 18/I-1954 ел. Басарга кул куелды 14/X-1954 ел. ПФ 30330.
Кәгазь форматы $70 \times 92^{1}/_{16}$. Учет-изд. 0,83 табак. Басма табак 1,0 (1,17). Табакта 37100 хәреф.
Заказ № 064. Тираж 20.000. Бәясе 60 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт № 9.




Нәни улы
этисенә
шундый бер сорау бирде:
— Эти, нәрсә ул
яхшы,
нәрсә ул
начар? — диде.
Сер итеп
саклыйсым юк,
кызыксынган балалар
этисенең
җавабын
бу китаптан
табарлар.


— Җил каерыр
түбәне,
боз явар,
кояш качар,
һәркем белә:
урамда
йөрү өчен бу —
начар.




Яңгыр үтте,
елмайды
җәйнең җылы кояшы, —
зурларга да,
нәниләр,
сезгә дә
бу — бик яхшы.



Берәүнең улы
шапшак,
бите-башы
корымлы,
моны инде
бик начар,
дип әйтсәк тә урынлы.



Бер бала
сабын сөя,
көн дә
тешен тазарта,
менә бу бала
яхшы, —
аны
һәркем ярата.



Була
сугыш чукмары,
нәниләрне
елата,
андыйларны
мин хәтта
язмас идем китапта.



Бусы менә:

— Тимә, — ди, —

кечкенә балаларга!

Бу малай

шундый яхшы,


сокланырлык аңарга!



Китапны
әгәр
ертсаң,
уенчыгыңны
бозсаң,
октябрятлар
сөйлиләр:
— Бу — начар малай, —
диләр.



Тырыш бала
эш сөя,
китапка
күңел сала.
Андыйны
бик мактыйлар;
ул менә
яхшы бала.




Карга күрсә
бер малай,
кычкырып,
куркып кача,
бу малай
куркак икән,
монсы инде
бик начар.



Каршы тора
бер бала,
курыкмый
усал коштан,
батыр икән,
бик яхшы,
батыр булыр
тормышта.



Бусы
    кергән пычракка,
үзе шуңа
    шатлана.
Андыйны
    яратмыйлар;
ул — начар,
    шапшак бала.



Бусы
юа галошын,
пимасын
үзе сөртә.
Нәни генә булса да,
Ул үзен
яхшы йөртә.

Онытмасын
hәр бала,
батыр булсын,
эшләсен,
чиста булсын,
укысын,
дуңгыз булып үсмәсен.
Малай китте
шатланып,
вәгъдә бирде ул шуннан:
„Мин
гел яхшы
булырмын,
hичвакыт
начар булмам“.



Бэясе 60 тиен